# Сәмигуллин Һадиулла Сәмигулла улы



Һадиулла абый үз гомерендә күпне күргән кеше булса да, сугыш еллары аның хәтерендә аерым урын алып тора. Өйрәнүләр лагере, фронт, әсирлек – ул җәһәннәм ачысын тулысы белән татыган. Боларга элекке хәрби әсир буларак, әйләнә-тирәдәгеләрнең шикләнеп каравын да өстәргә була. Сугыштан соңгы беренче елларда мондый мөнәсәбәт бигрәк тә нык сизелә. Һадиулла абый боларның барысына да түзгән, кешелек дәрәҗәсен саклап кала алган.

Кулына повестка тоттырганда ул унтугыз яшьлек егет була. Туган авылы Бикнараттан ике дусты белән бергә фронтка 1942 елның апрелендә китә. Аларны начар даны еракларга таралган Суслонгер лагере шикелле үк Ижевск өйрәнү пунктына китерәләр. Һадиулла абый әлеге лагерьда ничек яшәве турында сөйләгәндә күз яшьләремне көч-хәл белән генә тыеп тордым.

– Безне урманда урнашкан хәрби лагерьга алып килделәр. Анда күңелле каршы алдылар, дип әйтә алмыйм. Вакыты шундый катлаулы иде бит, – дип өсти Һадиулла абый, тиздән үлем белән йөзгә йөз очрашачак яшь егетләргә тиешле шартлар тудыру турында кайгыртмаучыларны аклаган кебек итеп. – Хәтта матрас та юк иде: каен чыбыкларын бергә тоташтырып үрдек тә, шунда икешәр кеше йокладык. Ашау ягы да бик начар булды, дөресен генә әйткәндә, ачлы-туклы яшәдек.

Биредә аларны атарга, һөҗүм итәргә өйрәтәләр. Өйрәнүләр арасында авыр хуҗалык эшләрен башкаралар. Йончыгып-талчыгып бетәләр, ял иттерү, тиешенчә ашату турында берәү дә кайгыртмый.Булачак солдатлар сәламәтлекләрен, физик һәм рухи көчләрен югалта баралар.

– Фронтка җибәрер алдыннан беркөнне безне, хәрби киемнәр киендереп, корал тоттырып, ерак арага походка озаттылар. Билгеләнгән урынга барып җиттек, өйрә-нүләр уздырдык, тик моннан соң инде кайберәүләр мөстәкыйль йөрерлек, кайтырлык хәлдә түгел иде, – ди Һадиулла абый. – Ярый әле берничә җигүле ат бар иде: коралларны һәм хәлсез солдатларны арбага төяп алып кайттык.

Һадиулла абый ничектер телгә алынмый калдырыла торган нәрсәләр турында да сөйләде. Аны тыңлаганда бәлки күп ветераннар нәкъ менә шушындый катлаулы вакытларны искә төшерергә теләмәгәнлектән сугыш турында сөйләргә яратмадылар һәм яратмыйлардыр, дип уйлап куйдым. Сугыш җиңү белән

тәмамланды бит, нигә авырлыклар турында искә төшереп торырга?

Сугыш Һадиулла өчен данлы Дон елгасы ярында башлана.
– Елганы кичү башланганчы өч кешегә бер винтовка бирделәр, һәркайсыбызга бишәр патрон өләштеләр, – диде Һадиулла абый, елмаерга тырышып. – Арабызда бер аучы бабай бар иде. Ул патроннарны бары үзенә генә бирергә кушты. Ул бик төз ата, бер дә тидерми калмый. Менә шушы карт солдат күпләребезнең гомерен саклап калды.

Солдат Һадиулла Сәмигуллинның хәрби тормышын җиңел дип әйтеп булмый. Дон ярларында озакка сузылган сугышлар бара. Немецлар көн саен җирдә дә, һавадан да безнең позицияләрне һөҗүмгә тоталар. Совет солдатлары җаннарын кызганмыйча каршы торалар. Каты сугышларның берсендә Сәмигуллин хезмәт иткән часть камалышта кала. Читтән ярдәм килеп җитми, үзләре камалышны өзеп чыга алмыйлар. Шулай итеп Һадиулла фронтташлары белән бергә әсирлеккә эләгә. Аларны Венгриягә алып китәләр һәм хәрби әсирләр лагерена ябалар. Мондагы хәлләр турында сораштырырга кыюлыгым җитмәде, чөнки Дон елгасын кичкәндә снайперларның яшь солдатларны берәмләп чүпләп атып үтерүләре турында сөйләгәндә үк Һадиулла абыйның тавышы да калтырый башлап, күзләре дә яшьләнгән иде инде.

Ветеранның кызы Гөлгенә:
– Аның әсирлектә кичергәннәрен хәтта дошманыңа да тели торган түгел. Аларны кыйныйлар да, ач та тоталар, газ җибәреп тә агулыйлар, ә инде ат урынына хәлдән килмәслек авыр эшләр эшләтүләре турында әйткән дә юк, – дип әйтеп куйды.

Безнең солдатларны әсирлектән американлылар коткара. Сугыш тәмамланырга инде күп калмаган була. Җиңүдән соң Һадиулла Сәмигуллин бер елдан артык вакыт Германиядә авточастьтә хезмәт итә, күзе начар күргәнлектән, шофер булып эшли алмый, аны санитар итеп куялар.

Өенә әйләнеп кайткач, колхозда төзелештә эшли башлый. Аның гомуми хезмәт стажы 62 ел.

1950 нче елда Гөлҗиһанга өйләнә. Алар 62 ел бергә бәхетле гомер итәләр, биш бала тәрбияләп үстерәләр. Ни кызганыч, моннан бер ел элек хатыны гүр иясе була. Бүген исәннәр арасында улы Рафик та юк. Һадиулла абыйның төп куанычы кызлары Сөмбелә, Гөлгенә, Наилә, Зөлхәбирә. Алты оныгы һәм өч оныкчыгы бар.



– Безнең әти – дөньяда иң

шәфкатьле, иң эшчән, иң кайгыртучан әти, – ди Гөлгенә. – Без аның ачуланганын, сүгенгәнен беркайчан да ишеткәнебез булмады. Начар гадәтләре дә юк, шуңа күрә безгә дә, балаларыбызга да матур үрнәк.

– Әти бик шәп балта остасы. Алар, өч туган – Габдулла, Һадиулла һәм Тәлгать, һәркайсына чиратлап, өч йорт салдылар. Аннан соң без үскән йортка янкорма төзеп куйдык. Әтиебезнең куллары алтын, ул йорт җиһазларын да үзе ясады, кайбер әйберләрдән әле дә файдаланабыз. Менә бу тумбочка безгә бик ошый, без аны саклап тотабыз, – диде Сөмбелә, истәлекле әйбергә күрсәтеп.

– Үзебезнең авылда да, күрше авылларда да әти салган йортлар байтак. Ул хәтта Шәпшегә һәм мари авылларына да йортлар салырга барып йөрде, – диде Гөлгенә.

**90 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Ветеранны тормышындагы шундый мөһим вакыйга белән Биектау муниципаль районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин һәм Шәүкәт Җәүдәт улы, Раушания Абдулловна котлады.**

